Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кибәк Иле авыл җирлеге башкарма комитеты

# КАРАР

12 март, 2020 ел № 5

2020 елгы язгы ташу чорында
Питрәч муниципаль районының
Кибәк Иле авыл җирлеге халкын
һәм территориясен саклау чаралары турында

2020 елгы язгы ташу чорында халыкны, хуҗалык һәм торак объектларын, гидротехник корылмаларны, юлларны һәм күперләрне саклау һәм «2020 елгы язгы ташу чорында Татарстан Республикасы халкын һәм территориясен саклау чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 31 гыйнварындагы 52 номерлы карарын үтәү максатларында Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кибәк Иле авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. 2020 елда Кибәк Иле авыл җирлеге территориясендә су басуга каршы чараларны гамәлгә ашыру буенча эшче төркем составын расларга.

2. Питрәч муниципаль районы Кибәк Иле авыл җирлеге территориясен 2020 елгы язгы ташу чорында халыкны һәм территорияне саклау буенча чаралар планын (алга таба - План) расларга.

3. Авыл җирлеге оешмалары, предприятиеләре һәм учреждениеләре җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

- 2020 елгы язгы ташуның тискәре нәтиҗәләрен кисәтү буенча План чараларын үтәүне тәэмин итәргә;

- биналарның һәм корылмаларның, склад һәм башка биналарның, юлларның, күперләрнең һәм гидротехник корылмаларның су басуын кисәтү буенча кичектергесез чаралар үткәрүгә аерым игътибар биреп, аларның үтәлешен даими контрольдә тотуны оештырырга;

- язгы ташу чорында җаваплы хезмәткәрләрнең тәүлек буе кизү торуын оештырырга.

4. Авыл җирлеге оешмалары, предприятиеләре һәм учреждениеләре җитәкчеләренә 2020 елның 20 мартыннан башлап көн саен Кибәк Иле авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә кар суларын үткәрүнең торышы һәм ведомство карамагындагы территориядә язгы ташуга әзерләнү һәм үткәрү буенча күрелә торган чаралар турында хәбәр итәргә тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Кибәк авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе И. М. Зиннуров

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КОБЯКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Кибәк авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе карары белән расланды 12.03.2020 ел № 5

2020 елда Питрәч муниципаль районы Кибәк Иле авыл җирлегендә ташуларга каршы чараларны гамәлгә ашыру буенча Кибәк Иле авыл җирлегенең эш төркеме составы

| № п\п | Фамилия, исеме, атасының исеме | Вазыйфа |
|---|---|---|
| 1. | Зиннуров<br>Илназ Минзахит улы | Эшче төркем җитәкчесе, Кибәк Иле авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе |
| 2. | Әхмәдуллина<br>Рузалия Фидаил кызы | Эшче төркем җитәкчесе урынбасары, Кибәк Иле авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре |
| **Эшче төркем әгъзалары:** | | |
| 3. | Гатауллина Гөлнара Гомәр кызы | Питрәч муниципаль районы «Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет учреждениесенең филиалы мөдире |
| 4. | Хуҗиәхмәтова Алсу Альбирт кызы | «Кибәк Иле башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе» филиалы мөдире |
| 5. | Сәйфетдинова Рәзинә Данил кызы | Кибәк Иле авыл мәдәният йорты директоры |
| 6. | Һидиятуллин Сәүбан Минзакир улы | Кибәк Иле авыл мәдәният йортының газ котельные операторы |

Кибәк авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе карары белән расланды
12.03.2020 ел № 5

**Кибәк Иле авыл җирлегенең 2020 елгы язгы ташу чорында халыкны һәм территорияләрне саклау чаралары турында**

**П Л А Н**

| № | Чаралар исеме | Үтәү вакыты | Башкаручылар |
|---|---|---|---|
| 1 | Язгы ташу аркасында килеп чыккан гадәттән тыш хәлләр вакытында үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен халыкка җиткерү. | ташу башланганчы | Эшче төркем |
| 2 | Автомобиль юллары, күперләр, юлсызлык вакытында керү юллары торышын тикшереп торуны оештыру | ташу башланганчы | Эшче төркем |
| 3 | Язгы ташу сулары белән су басуга эләгә торган авыл хуҗалыгы объектларын һәм үләт базларын тикшерү | 25.03.2020 кадәр | Эшче төркем |
| 4 | Максималь күләмдә кар суларын үткәрү өчен юллардагы су үткәргеч торбаларны, каналларны, яңгыр сулары канализациясе корылмаларын чистарту буенча чаралар үткәрүне оештыру | ташу башланганчы һәм ташу вакытында | АҖ Башкарма комитеты |
| 5 | Сулыкларда су дәрәҗәсен күзәтүне оештыру | Ташу вакытында | Эшче төркем |
| 6 | Зыян күргән кешеләргә медицина ярдәмен күрсәтүне оештыру буенча әзерлек эшләре үткәрү | Ташу вакытында | АҖ Башкарма комитеты, ФАП мөдире |
| 7 | Мөмкин булган су басу зонасына керә торган торак биналардан һәм корылмалардан кар суларын чыгару буенча эшләрне оештыру | Ташу вакытында | АҖ Башкарма комитеты, Мәктәп директоры, АМЙ, ФАП мөдире, китапханә |

Кибәк Иле авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе И. М. Зиннуров